**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ УЛЬЯНОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Центральная ул., 44 дом, Ульяновка село, 423115 тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17; email: Ul.Cmn2@tatar.ru Үзэк урамы, 44 йорты, Ульяновка авылы, 423115

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Ульяновка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№ 39** **07 сентябрь 2021ел**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Чирмешән муниципаль районы прокурорының «Шәһәр төзелеше законнарын бозуларны бетерү турында» 2021 елның 10 августындагы күрсәтмәсен карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советының 2018 елның 6 августындагы 86 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Ульяновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын әзерләү, раслау тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары;
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 декабрендәге 104 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы «Ульяновка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын раслау турында» карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән

муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге
башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары Федулова И.В.